ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

икенче утырыш

09 октябрь 2020 ел № 10 Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүне раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Теләче муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 2020 елның 17 августындагы 10-53/10213 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 27 декабрендәге 186 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Теләче муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланган документны урнаштырырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов